КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 октябрь г.Казань № 893

Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибе турында

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 29 июнендәге б-1725 номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибен;

Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкның бердәй үрнәген раслауга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган, Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкны яңадан рәсмиләштерү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкларны әзерләүне һәм бирүне;

территориаль социаль яклау органнарының эш итү карамагында кирәкле документлар һәм белешмәләр булганда, Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган, Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкларны яңадан, шул исәптән гариза бирелмәгән тәртиптә рәсмиләштерүне.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республика-

сында күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 1999 ел, 3 август, 476 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2004 ел, 17 декабрь, 540 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 6 декабрь, 693 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2012 ел, 23 июнь, 545 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 23 ноябрь, 1052 нче карарындагы 1 пункт;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 ел, 11 март, 214 нче карарындагы 1 пункт;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 6 май, 422 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2024 ел, 6 июнь, 410 нчы карары.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 17 октябрь, 893 нче
карары белән расланды

Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын
раслый торган таныклык бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык (алга таба – таныклык) бирү тәртибен билгели.

2. Таныклык алу хокукына күпбалалы гаилә ия.

3. Таныклык бирү гариза бирүченең Татарстан Республикасында яшәү (булу) урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек)) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Таныклыкны рәсмиләштергәндә күпбалалы гаилә составында күпбалалы гаилә әгъзаларының барысы да Россия Федерациясе гражданы булу һәм ир белән хатынның берсе (бердәнбер ата йә ана) һәм аларның кимендә өч баласы Татарстан Республикасы территориясендә яшәү (булу) урыны буенча теркәлү шарты белән түбәндәгеләр исәпкә алына: фактта яшәүче һәм анда 18 яшькә кадәрге һәм (яки) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге укуда белем алу шарты белән 23 яшькә кадәрге балалар, шулай ук белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада уку белән бәйле рәвештә ата-аналарыннан аерым яшәүче әлеге балалар категорияләрен тәрбияләүче ир белән хатын (бердәнбер ата йә ана).

5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча таныклык бирү турында гариза (алга таба – гариза) ир белән хатынның берсе (ата-аналар аерым яшәгән очракта – закон көченә кергән баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында суд карары яки ата-ана арасында килешү нигезендә балалары яши торган ата-ананың берсе) яки ышанычнамә нигезендә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат (алга таба – гариза бирүче) тарафыннан гариза бирүченең Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) түбәндәге юл белән тапшырыла:

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, шулай ук «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша;

почта аша җибәреп;

шәхсән.

Идарәдә (бүлектә) теркәлгән гариза булганда, шул ук гариза бирүче тарафыннан кабат тапшырылган гариза карап тикшерелми.

6. Гариза бирүченең тормыш хәле нинди булуына карап, гаризага түбәндәге

документлар теркәлә:

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән никахлашуны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

закон көченә кергән баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында суд карары яки ата белән ана аерым яшәгәндә ата-ана арасында баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында килешү күчермәсе;

таныклыкны бирү датасы гариза тапшырылган датага карата 60 календарь көннән артмаган, 18 яшьтән 23 яшьгә кадәрге баланың һөнәри белем бирү оешмасында, югары белем бирү мәгариф оешмасында яки белем бирүне гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча уку факты турында белешмә кәгазе күчермәсе;

баланы уллыкка алу турында суд карары күчермәсе;

Россия Федерациясеннән читтә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча уку турында чит ил дәүләте территориясендә бирелгән документ һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

гариза бирүченең һәм аның хатынының (иренең) 3 × 4 см зурлыгында фотосурәте.

Мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче үз шәхесен раслый торган документ күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар нотариаль таныкланмаган булса, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана. Документларның күчермәләре бер нөсхәдә бирелә.

Идарәгә (бүлеккә) почта аша гариза җибәрелгән очракта, гаризага нотариаль таныкланган документларның күчермәләре теркәлә.

Гариза бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган документларның дөреслеге өчен җавап бирә.

7. Идарә (бүлек) ведомствоара рәсми сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып электрон рәвештә вәкаләтле оешмалардан түбәндәге белешмәләрне ала:

бала туу турында;

никахлашу (никахны таркату) турында;

гариза бирүченең һәм балаларның Россия Федерациясе территориясендә яшәү (булу) урыны буенча теркәлүе яисә теркәлмәве турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында;

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланың гомуми белем бирү оешмасында укуы турында;

шәхесне таныклый торган документның гамәлдә булуы турында.

Гариза бирүче үз инициативасы белән Идарәгә (бүлеккә) әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләргә ия документларны тапшырырга хокуклы.

8. Таныклык бирү (таныклык бирүдән баш тарту) турында карар Идарә (бүлек) тарафыннан гариза теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә кабул ителә.

Таныклык бирү (таныклык бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәрнамә гариза бирүчегә таныклык бирү (таныклык бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән җиткерелә.

10. Таныклык бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

әлеге Тәртипнең 2 һәм 4 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килми торган зат мөрәҗәгать итү;

дөрес булмаган белешмәләргә ия документлар тапшыру;

гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар (белешмәләр) әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләр эчтәлегенә һәм формасына туры килмәү.

10. Таныклыкка Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имза куела һәм ул мөһер белән таныклана.

11. Таныклык, гариза бирүчегә таныклык бирү турында хәбәрнамә җибәрелгәннән соң, гариза бирүче әзер таныклыкны алу өчен мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Әгәр гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) электрон документлар формасында җибәрелгән булса, таныклык фотосурәт белән гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

12. Бирелә торган таныклыклар Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан таныклыкларны исәпкә алу журналына теркәлә һәм гариза бирүчегә шушы журналга кул куйдырып бирелә.

13. Гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме үзгәргән, гаилә әгъзалары вафат булган, ата-ананың (ата-аналарның) гаилә хәле үзгәргән очракта, гариза бирүче, әлеге Тәртип нигезендә, элек бирелгән таныклыкны өстәп, гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

14. Таныклык югалган яки бозылган очракта, «дубликат» билгесе куелып, таныклык дубликаты бирелә. Таныклык дубликатын бирү турында гариза формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан раслана.

Таныклык дубликатын бирү турындагы гаризаны карап тикшерү, таныклык дубликатын бирү турында карар кабул итү һәм таныклык дубликатын бирү таныклык бирү өчен каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

15. Бала (балалар) туган (уллыкка алган) очракта, гариза бирүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча таныклыкка үзгәрешләр кертү турындагы гариза белән яшәү (тору) урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итә,

таныклыкны һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы тугызынчы абзацында күрсәтелгән документны тапшыра.

Бала (балалар) Россия Федерациясеннән читтә туган очракта, гариза бирүче чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсенең күчермәләрен тапшыра.

Баланы (балаларны) уллыкка алган очракта, гариза бирүче баланы (балаларны) уллыкка алу турында суд карары күчермәсен бирә.

Бала (балалар) туган (уллыкка алган) очракта таныклыкка үзгәрешләр кертү турында гаризаны карап тикшерү таныклык бирү өчен каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 17 октябрь, 893 нче
карары белән расланды

Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкның бердәй үрнәген раслауга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган, Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкны яңадан рәсмиләштерү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип, Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкның бердәй үрнәген раслауга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган, Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкны (алга таба – таныклык) яңадан рәсмиләштерү кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча таныклыкны яңадан рәсмиләштерү турында гариза (алга таба – гариза) яшәү (булу) урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) гариза бирүче яки ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат тарафыннан бирелә.

Гариза бирүченең тормыш хәле нинди булуга карап, гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән никахлашуны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

закон көченә кергән баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында суд карары яки ата белән ана аерым яшәгәндә ата-ана арасында баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында килешү күчермәсе;

таныклыкны бирү датасы гариза тапшырылган датага карата 60 календарь көннән артмаган, 18 яшьтән 23 яшьгә кадәрге баланың һөнәри белем бирү оешмасында, югары белем бирү мәгариф оешмасында яки белем бирүне гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча уку факты турында белешмә кәгазе күчермәсе;

баланы уллыкка алу турында суд карары күчермәсе;

чит ил дәүләте территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

гариза бирүченең һәм аның хатынының (иренең) 3 × 4 см зурлыгында фотосурәте;

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык.

Мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче үз шәхесен раслый торган документ күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булса, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана. Документларның күчермәләре бер нөсхәдә бирелә.

Гариза Идарәгә (бүлеккә) почта аша җибәрелергә мөмкин. Бу очракта гаризага Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган документларның күчермәләре теркәлә.

Гариза бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган документларның дөреслеге өчен җавап бирә.

3. Гаризаны карап тикшерү, таныклыкны яңадан рәсмиләштерү турында карар кабул итү һәм яңадан рәсмиләштерелгән таныклык бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибе турында» 2024 елның 17 октябрендәге 893 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибендә каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Таныклыкны яңадан рәсмиләштерү, Идарәнең (бүлекнең) эш итү карамагында кирәкле документлар һәм күпбалалы гаилә статусына ия затларның белешмәләре булганда, гариза бирелмәгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.